РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШИКШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422053, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Шикши, ул. Школьная, д.4
тел. (84362) 46-1-35

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕКШЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422053, Татарстан Республикасы, Саба районы, Шекше авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт
тел. (84362) 46-1-35

e-mail:Shik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
02.06.2021

КАРАР
№13

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының 25.03.2013 ел, № 11 карары белән расланган Шекше авыл җирлегендә гражданнар тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына ана (гаилә) капиталы средстволарын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» гы № 35-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1.Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының 25.03.2013 ел, № 11 «Гражданнар тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны Шекше авыл җирлегенә муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турында" гы карары белән расланган Шекше авыл җирлеге Советы тарафыннан хосусыйлаштырылган торак биналарны гражданнар тарафыннан муниципаль милеккә тапшыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«2.1. хосусыйлаштырылган торак урыннарны Шекше авыл җирлеге муниципаль милкенә тапшырырга теләгән гражданнар, Шекше авыл җирлеге башкарма комитетына торак урынының барлык милекчеләре тарафыннан имзаланган, гражданның шәхесен таныклаучы документның төп нөсхәсен күрсәтеп, Шекше авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гариза тапшыралар. Гаризага муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты белән билгеләнә торган документлар теркәлә.»

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shikshi адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Шекше авыл җирлеге башлыгы Хәйртдинов Р.Р.